СОВЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 3, с.Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

**«27» гыйнвар 2025 ел** **№1**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына кергән ришвәтчелек юнәлешендәге мөрәҗәгатьләр белән эшләү тәртибен раслау турында**

“Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турындагы” 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына кергән ришвәтчелек юнәлешендәге мөрәҗәгатьләр белән эшләү тәртибен расларга.

2. Ришвәтчелек юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүче вазыйфаи затларны хезмәт мәгълүматларының һәм шәхси характердагы белешмәләрнең сакланышы өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Яңа Кырлай авыл җирлеге
башлыгы Карарына
Кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлегенең ришвәтчелек фактлары буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип "Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында" 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 статьясын үтәү йөзеннән эшләнгән һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына кергән ришвәтчелек юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау үзенчәлекләрен билгели (алга таба – Тәртип, җирле үзидарә органнары), үз эченә ришвәтчелек һәм янап куркыту фактлары, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен кысу, хезмәт тәртибенә таләпләрне бозу, шулай ук хезмәт урыныннан явызларча файдалану билгеләре булган башка гамәлләр турындагы белешмәләрне (алга таба – мөрәҗәгать) ала.

2. Мөрәҗәгать "Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турындагы" 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законда һәм әлеге Тәртиптә билгеләнгән тәртиптә һәм вакыт чикләрендә теркәлә һәм карала.

Мөрәҗәгатьтә әзерләнә торган, башкарыла торган яисә башкарылган хокукка каршы гамәл турында, шулай ук аны әзерләүче, башкаручы яисә башкарган зат турында белешмәләр булганда, мөрәҗәгать аларның компетенциясе буенча хокук саклау органнарына җибәрелергә тиеш.

Мөрәҗәгать карарлары яисә гамәлләре (гамәл кылмавы) мөрәҗәгать предметы булган дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка җибәрелми.

Гражданнар мөрәҗәгатен ришвәтчелек юнәлешендәге фактлар буенча караганда мөрәҗәгатьләрдәге белешмәләрне, шулай ук гражданның хосусый тормышына кагылышлы белешмәләрне аның ризалыгыннан башка ачу рөхсәт ителми. Карала торган мәсьәләнең барлык шартлары ачыкланганчы мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә кергән вазыйфаи затка язма мөрәҗәгатьне җибәрү мөрәҗәгатьтәге белешмәләрне ачу булып тормый.

3. Мөрәҗәгатьтә муниципаль хезмәткәрнең муниципаль хезмәткә бәйле бурычларны, чикләүләрне һәм тыюларны, шулай ук хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәмәве, муниципаль хезмәткәрнең мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы булуы, мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килүе, муниципаль хезмәткәрнең башка

коррупцион хокук бозулар кылу ихтималы турында мәгълүматлар булган очракта, район җирле үзидарә органы җитәкчесе мөрәҗәгатьтә бәян ителгән фактларга карата тикшерү үткәрүнең максатка ярашлылыгы турында Карар кабул итә. Әлеге тикшерү хезмәт тәртибенә карата таләпләрнең үтәлешен (муниципаль хезмәткәрләрнең “Ришвәтчелеккә каршы тору турындагы” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, башка федераль законнар белән туктатылган чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәвен, аларның бурычларын үтәвен) тикшерү булып тора һәм Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 2нче февралендәге УП-71 номерлы “Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвен тикшерү турындагы” Указы нигезендә уздырыла.

4. Күрсәтелгән тикшерү үткәргәндә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәттәге үз-үзен тотышына һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәвен раслый торган фактлар билгеләнгән очракта, районның җирле үзидарә органы җитәкчесе Тикшерү материалларын Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында хезмәттәге (вазыйфаи) үз-үзен тотышына һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу таләпләрен үтәү комиссиясенә бирү турында Карар кабул итә. (алга таба – Комиссия).

5. Күрсәтелгән мәсьәләне карау турында Карар кабул ителгәндә комиссия утырышында утырышның датасы, вакыты һәм урыны билгеләнә, шулай ук норматив хокукый актлар нигезендә Комиссия утырышын әзерләү эше оештырыла.

6. Мөрәҗәгатьтә куелган сорауларның асылы буенча мөрәҗәгать итүчегә җавап үткәрелгән чараларның һәм тикшерүләрнең нәтиҗәләре турында, комиссия карарлары турында (булган очракта), шулай ук кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән муниципаль хезмәткәргә карата җаваплылык чаралары куллану турында йә тикшерү үткәрү өчен нигезләр булмау турында һәм коррупция фактларын расламау турында мәгълүмат бирергә тиеш.